Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Табар Черкене авыл җирлегенең Пүчинкә-Енай авылында гражданнар җыенының "Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Табар Черкене авыл җирлегенең Пүчинкә-Енай авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре һәм 2021 елда үзара салым кертү турында" 2020 елның 10нчы ноябрендәге 2нче номерлы карары

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Табар Черкене авыл җирлегенең Пүчинкә-Енай авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән (көндезге формада белем алучы студентлардан, балачактан инвалидлардан, коляскада йөрүче инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, күп балалы гаиләләрдән тыш), 500 (биш йөз) сум күләмендә 2021 елда үзара салым кертүгә рөхсәт итәсезме »дигән мәсьәлә буенча 2020 елның 10нчы ноябрендә Пүчинкә-Енай авылы гражданнары җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде,һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкарырга җибәрергә:

-Пүчинкә-Енай авылының 1 Май урамы буенча вак таш җәю һәм җирле әһәмияттәге юлларны карап тоту;

«ӘЙЕ» «ЮК»

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 57 кеше кертелгән, җыенында тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 35 кеше .

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенында катнашучы гражданнар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен җыенда 35 кеше тавыш бирде;

«юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены түбәндәгечә карар итте:

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы составына керүче Табар Черкене авыл җирлегенең Пүчинкә-Енай авылында халык җыенын узган дип, халык җыенының нәтиҗәләре дөрес дип танырга.

2.« Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Табар Черкене авыл җирлегенең Пүчинкә-Енай авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән (көндезге формада белем алучы студентлардан, балачактан инвалидлардан, коляскада йөрүче инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, күп балалы гаиләләрдән тыш), 2021 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме дигән мәсьәлә буенча карар кабул ителгән дип танырга һәм - түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлдерергә:

-Пүчинкә-Енай авылының 1 Май урамы буенча вак таш җәю һәм җирле әһәмияттәге юлларны карап тоту;

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Табар Черкене авыл җирлегенең Пүчинкә-Енай авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә (көндезге уку формасы буенча укучы студентлар, балачактан инвалидлар; коляскалы инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, күп балалы гаиләләрдән тыш) 2021 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә үзсалым кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

-Пүчинкә-Енай авылында 1 Май урамы буенча вак таш җәю һәм җирле әһәмияттәге юлларны карап тоту;

«ӘЙЕ» «ЮК»

4.Гражданнар җыенының нәтиҗәләрен мәгълүмат стендында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында игълан итәргә.

Халык җыены рәисе Ибәтуллин Р.Х.
Халык җыены сәркатибе Сусарина О.Н.